**СОВЕТ**
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“08” ноябрь 2019ел** **№ 109**

**Арча район Советының 2018 елның 20декабрендәге 82 номерлы карары белән расланган (2019 елның 16 апрелендәге 88 номерлы үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районы “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

“Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясына үзгәрешләр кертелү сәбәпле, Утар-Аты авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Арча район Советының 2018 елның 20 декабрендәге 82 номерлы карары белән расланган (2019 елның 16 апрелендәге 88 номерлы үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районы “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Нигезләмәнең 15.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Утар-Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр урамы, 6 йорт; ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 1

йорт адреслары буенча халыкның күплəп җыела торган урыннарындагы мəгълүмат стендларына урнаштыру юлы белəн халыкка игълан итəргə.

3. Әлеге карарның үтəлешен тикшереп торуны үз өстемə алам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы: А.Г. Мөхəммəтгалиева